Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлеге составына керүче Трудовой торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2021 елның 28 октябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлегенең Трудовой торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Майская Горка авыл җирлеге Трудовой торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә, ә 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар һәм күп балалы гаиләләр өчен түләүләр күләме гражданнар җыены карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.
2. Алынган акчаларны мәктәп урамы буенча тротуар һәм җәяүлеләр юлы төзүгә (тротуар өчен грунт эшләү, борт ташлары монтажлау, тротуар урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү) һәм буаны төзекләндерү (дамбаны ныгыту, буа төбен чүп-чардан арындыру, килешү буенча эшләр өчен түләү) юнәлдерергә.

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлеге составына керүче Трудовой торак пунктында гражданнар җыенының 14.11.2019 елның 2нче номерлы карары нигезендә Трудовой торак пунктында балалар мәйданчыгын төзекләндерү өчен җыелган үзара салым акчаларын, Трудовой бистәсендә буаны төзекләндерүгә юнәлтергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Майская Горка авыл җирлеге башлыгы А.П. Морозов